РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ ТИМЕРШИКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422057, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Тимершик, ул. Пионерская, 19 а
тел. (84362) 2-23-23

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ТИМЕРШЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

422057, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Тимершык авылы, Пионер урамы, 19 а йорт
тел. (84362) 2-23-23

e-mail: Timer.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
04.06.2021

КАРАР
№16

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Тимершык авыл җирлеге Советының
25.02.2021 елгы 7 номерлы карары белән расланган
Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә
һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге
җирләргә Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Тимершык авыл җирлеге территориясендә
яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы Нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы прокуратурасының 27.05.2021 нче елгы таләбе нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге территориясендә яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында, Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән җирләр, 2021 елның 25 февраленда 7 номерлы Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге территориясендә, Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә кермәгән физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» гы карары белән расланган кararга түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3.14 пунктында «рөхсәт ителергә мөмкин» сүзләрен “рөхсәт ителә» сүзләре белән алмаштырырга;

1.2. Нигезләмәнең 3.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8. Авыл җирлеге Башкарма комитетына мөрәҗәгать итүченең хат-гаризасы, яшел үсентеләрне техник тикшерү акты, киселгән агач өчен бәяне

(түләүне) 10 эш көне эчендә авыл җирлеге Башкарма комитетының авыл җирлеге территориясендә яшел үсентеләр кисүгә рөхсәт бирү турындагы карары проектын әзерли.»;

1.3.Нигезләмәнең 3.9. пунктын түбәндәге эчтәлекле икенче җөмлә белән тулыландырырга: «Киселгән агач өчен бәя (түләү) исәпләү. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 22.05.2007 елгы 310 номерлы карары белән расланган «Урман ресурслары күләме бирәмлеге өчен түләү ставкалары һәм федераль милектә булган урман кишәрлеге мәйданы берәмлеге өчен түләү ставкалары турында» карары нигезендә исәпләнә.».

2.Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/rus/timershik адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Тимершык авыл
җирлеге башлыгы А.Х. Хаҗиев